ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.02.2026 ел Баулы шәһәре №30

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Педагогик хезмәткәрләргә – Баулы муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Баулы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән ай саен кызыксындыру өстәмәсе бирү тәртибе турында» 2019 елның 26 августындагы 250 номерлы карарына (2022 елның 22 декабрендәге 269 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен кызыксындыру өстәмәсе билгеләү турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 21 ноябрендәге 979 номерлы карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Педагогик хезмәткәрләргә – Баулы муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Баулы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән ай саен кызыксындыру өстәмәсе бирү тәртибе турында» 2019 елның 26 августындагы 250 номерлы карарына (2022 елның 22 декабрендәге 269 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 пунктта «2 510 сум» саннарын һәм сүзләрен «10 000 сум» саннарына һәм сүзләренә алмаштырырга;

педагогик хезмәткәрләргә – Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Баулы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән ай саен кызыксындыру өстәмәсе бирү Тәртибендә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр - яшь белгеч дип төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча укуын тәмамлаган, алган квалификациясе нигезендә беренче тапкыр эшкә урнаша торган, шул исәптән төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча уку чорында алган хезмәт стажы булган Россия Федерациясе гражданы танила.»;

4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«һөнәри белем бирү оешмалары.»;

11 пунктта «08.08.2013 №678» саннарын «21.02.2022 №255» саннарына алмаштырырга;

14 пунктта:

- икенче һәм өченче абзацларда «2 510 сум» саннарын һәм сүзләрен «10 000 сум» саннарына һәм сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

- икенче һәм өченче абзацларда «2 510 сум» саннарын һәм сүзләрен «10 000 сум» саннарына һәм сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров